Урта гасырларда ук тәнкыйди фикер үз жанрларын булдырырга омтыла. Бу вакыттагы болгар-татар кульязма истәлекләрендә, ядкәрләрендә каләмдәшләре әсәрләрен бәяләү, тамгалау традициясе яшәгән. Шулай ук **шәрех** (аңлатма), **хашияләр**, **"бәйләү"ләр** (китап бите кырыендагы искәрмәләр) язу гадәте киң таралыш ала. XIX гасырның соңгы чирегендә **мәкалә, рецензия** әдәби тәнкыйть жанрлары буларак калыплашуның беренче адымнарын ясый. Аерым алганда, XIX гасырның урталарында Аурупа-рус мәдәниятенә йөз белән борылган мәгърифәтче галим, әдип К. Насыйриның өстәл календарьларенда, әдәби-гыйльми эшчәнлегендә һәм Бакчасарайда Исмәгыйль Гаспралы нәшер иткән "Тәрҗеман" газетасы битләрендә бу жанрларның тәүге үрнәкләре тудырыла. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән **тәгъзия** дә үзенең тамырлары белән борынгы бабаларыбызның мәдәни – тарихи культурасына барып тоташа.

Шулай да әдәби тәнкыйтьнең жанр ягыннан үсүе, баюы XX гасыр башларына туры килә. Гыйльми-тәнкыйди фикердә жанрлар мәсьәләсе теоретик проблема буларак көн тәртибенә куела. Мәгълүм булганча, рецензия, мәкалә әдәби тәнкыйтьнең классик жанрларыннан исәпләнә. Ф. Әмирханның "Әльислах" газетасы белән бәйле журналистлык һәм тәнкыйди эшчәнлеге аша рецензия жанры, аның төрле формалары: монорецензия, күзәтү рецензиясе, кыска рецензия, аннотация, мәкалә – рецензия һ.б. әдәби тәнкыйди мәйданда тулы хокук яулый. Г. Ибраһимов "Әдәбият кануннары" (1919) дигән китабында **рецензия, рәддия һәм мәкаләне** әдәби тәнкыйтьнең жанрлары буларак карый [2:108].

Аерым бер әдипләрнең тәнкыйди эшчәнлегендә Шәрекъ дөньясыннан үтеп кергән **тәкъриз (**рецензия**), мөрасәлә (**хат**), мөхабәрә** (хәбәрләр) терминнары фәнни әйләнештә йөри. Әмма бу жанр атамалары заман сынавын үтә алмыйча төшеп калалар. Тәнкыйди жанрларның төрлелеге һәрбер әдип, тәнкыйтьче иҗатында күзәтелә. Шулай да бу өлкәдә Г. Тукай кызыклы тәҗрибәләр ясый [1:23].

